**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯШЕЛ ҮЗӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ӨТӘШКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

2021 елның 24 мае 34

Өтәшкә авыл җирлеге Советы карарларының үз көчен югалтуын тану турында

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районының «Өтәшкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына, Яшел Үзән муниципаль районы составына керүче «Өтәшкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең милек белән идарә итү, аннан файдалану, җир кишәрлекләре белән эш итү буенча вәкаләтләренең бер өлешен, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына бирү өчен билгеләнгән мөлкәт исемлеген «Яшел Үзән муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшыруга бәйле рәвештә, «Өтәшкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Өтәшкә авыл җирлеге» муниципаль хокукый актлар системасын актуальләштерү максатларында, Өтәшкә авыл җирлеге Советы **карар кылды:**

1. Өтәшкә авыл җирлеге Советы карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

- Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы «Өтәшкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең муниципаль милкен хосусыйлаштыру тәртибе турында" 2016 елның 28 июнендәге 47 номерлы карары»;
- 2017 елның 19 декабрендәге 103 номерлы «Өтәшкә авыл җирлеге Советының 2016 елның 28 июнендәге 47 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турындагы «Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы «Өтәшкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең муниципаль милкен хосусыйлаштыру тәртибе турында»гы карары»;
- 2019 елның 30 июлендәге 174 номерлы «Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районының «Өтәшкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең 2016 елның 28 июнендәге 47 номерлы Өтәшкә авыл җирлеге Советы карары белән расланган муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында»;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Яшел Үзән муниципаль

районы рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук Өтәшкә авыл җирлегенең мәгълүмати стендларда түбәндәге адреслар буенча: Өтәшкә авылы, Нагорная урамы, 99а (җирлек администрациясе бинасы), Өтәшкә авылы, Үзәк урамы, 40а (мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

**Өтәшкә авыл җирлеге башлыгы, Совет рәисе:** **А.А. Клопов**